ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ХОЗЕСАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 июль 2023ел. Хуҗа Хәсән ав. №29

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге ягыннан капиталь инвестицияләрне яклау һәм хуплау турында килешүләр төзү шартлары һәм тәртибе турында» 2021 елның 16 декаберенең 13 номерлы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә капиталь кертемнәрне яклау һәм хуплау турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 28 июнендәге 226-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге ягыннан капиталь инвестицияләрне яклау һәм хуплау турында килешүләр төзү шартлары һәм тәртибе турында» 2021 елның 16 декаберенең 13 номерлы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәнге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктта:

6 нчы пунктчада «транспорт салымы», һәм «,автомобильләргә җиңел һәм мотоциклларга акцизлар» сүзләрен чыгарырга;

түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча белән тулыландырырга:

«10) проектны гамәлгә ашыручы оешманың капиталь кертемнәрне яклау һәм хуплау турында килешү төзелгәннән соң өч ел эчендә салым мониторингы формасында салым контроленә кучү бурычы.»;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районы авыл җирлегенең https://hozesan-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитеты
Җитәкчесе

С.П. Матвеева